| | | |
|---|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**<br>**ГЛАВА СТАРОАЛЬМЕТЬЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**<br>**НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСКЕ ӘЛМӘТ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**<br>**БАШЛЫГЫ** |

---

| | | |
|---|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | Иске Әлмәт ав. | **КАРАР** |

«09» ноябрь 2022 ел № 2

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлеге Яңа Әлмәт авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Иске Әлмәт авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Иске Әлмәт авыл җирлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2022 елның 26 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка Яңа Әлмәт авылы, Мәктәп урамы, 20 нче йорт адресы буенча урнашкан «Юлдаш» кибете янында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлеге Яңа Әлмәт авылында яшәүчеләр өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын уздыруны билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Иске Әлмәт авыл җирлеге Иске Әлмәт авылында халык җыены этапларын үткәрү һәм оештыру белән Иске Әлмәт авыл җирлеге башлыгы һәм Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Иске Әлмәт авыл җирлеге башкарма комитеты тәэмин итә.

5. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2023 елда Нурлат муниципаль районының Иске Әлмәт авыл җирлеге Яңа Әлмәт авылы территориясендә теркәлү урыны буенча яшәүче, 1нче төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан кала, балигъ булган һәр кешедән 1500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм әлеге акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрне башкару буенча мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Иске Әлмәт авыл җирлеге чикләрендә юлларны карап тоту, грейдер белән тигезләү һәм киләчәктә яшелләндерү өчен тыгыз нигез салу,

- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Иске Әлмәт авыл җирлеге чикләрендә юл полотносы профилен үзгәртеп, вак таш сатып алу хезмәтләре өчен түләү,

- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Иске Әлмәт авыл җирлеге өчен МТЗ - 82.1 тракторы һәм тагылмалы җиһазлар сатып алу.

«РИЗА» «КАРШЫ».

6. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru., Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында района http://nurlat.tatarstan.ru, Иске Әлмәт авыл җирлегенең Иске Әлмәт авылы мәгълүмат стендларында гражданнар җыены этапларын үткәрү датасына 10 көннән дә соңга калмыйча бастырып чыгарырга (игълан итәргә).

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Иске Әлмәт авыл җирлеге башлыгы Хисамов Р.Г.